# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

“Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 5 һәм 18 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында” 2010 елның 29 мартындагы 29-ФЗ номерлы Федераль законны һәм Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә Юлламасын гамәлгә ашыру максатларында "Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында" 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш); 2008, № 1, № 12 (VI өлеш); 2009, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

9 статьяда:

2 пунктта түбәндәге эчтәлекле яңа җиденче абзац өстәргә:

“Татарстан Республикасы Дәүләт Советына “Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 18 статьясындагы 7 пунктында каралган еллык юлламалар (хисаплар) тапшыра;”;

җиденче – унберенче абзацларны тиешенчә сигезенче – уникенче абзацлар дип санарга;

түбәндәге эчтәлекле 5, 6, 7 пунктлар өстәргә:

“5. “Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 18 статьясындагы 7 пунктында каралган еллык юлламалар (хисаплар) Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына агымдагы елның 15 октябреннән дә соңга калмыйча тапшырыла.

6. Еллык юлламаларны (хисапларны) әзерләү законнарда каралган тәртиптә башкарыла.

7. Еллык юлламаларның (хисапларның) “Республика Татарстан” һәм “Ватаным Татарстан” газеталарында рәсми бастырып чыгарылуы мәҗбүри.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты. Гомуми бүлек. Общий отдел

Казан, Кремль
2010 елның 30 июле
№ 57-ТРЗ